| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2022 елның 15 августы** с.Кугушево **№ 86**

Күгеш авыл җирлеге Советының аерым норматив-хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Күгеш авыл җирлеге Советының мәгълүматларын һәм норматив-хокукый актларын актуальләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Күгеш авыл җирлеге Советы карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- 2007 елның 15 мартындагы 72 номерлы "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “Күгеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;
- 2011 елның 6 августындагы 46 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне аукционда сату тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 нче йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а нче йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.А. Гатауллин**